# Төсле яңгыр

Яшел яңгыр, яшел яңгыр,
Таллыклар арасында.
Кызыл яңгыр, кызыл яңгыр,
Комлы тау арасында.

*Куш: Яу яңгыр, яу яңгыр,*
*Ялындырмый яу әле!*
*Тамчыларыңны биетеп,*
*Яле, яле яу әле!*

Зәңгәр яңгыр, зәңгәр яңгыр,
Инеш дулкыннарында-
Сары яңгыр, сары яңгыр
Якты бодай кырында.

*Кушымта.*

Болыт җиргә җепләр сузып,
Төсләрдән чигү чигә.
Бизәкле келәм әзерли,
Бүләккә игенчегә.

*Кушымта.*